**Г.Р.Гайнуллина**

**Казанский (Приволжский) федеральный университет, г. Казань**

# Ф.ХӨСНИНЕҢ БАЛАЛАР ӨЧЕН ЯЗЫЛГАН СУГЫШ ҺӘМ СУГЫШТАН СОҢГЫ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ СУРӘТЛӘНГӘН ДӨНЬЯ

Татар балалар әдәбияты XX йөз башында формалаша һәм төрле юнәлешләр белән үсеш ала [Минһаҗева 2011: 3]. “1940-1960 еллар шартларында үзгә сәяси җирлекләрдә үсүен дәвам иткән балалар әдәбиятының темалары, сурәтләү объекты, стиль үзенчәлекләре шул чордагы төп әдәби юнәлешләрдә ачык чагыла” [Минһаҗева 2011: 7].

Сугыш һәм сугыштан соңгы (1940-1960) татар балалар прозасында Фатих Хөсни иҗаты аерым урында тора. Әдипнең “Карлыгач” (1945), “Малай белән солдат” (1956) хикәяләрендәге сюжет турыдан-туры Бөек Ватан сугышы вакыйгалары белән бәйләнә.

Ф.Хөснинең “Карлыгач” (1945) хикәясе көчле позициядә мифопоэтик образны уйнатуга корылган. Улының сугыштан кайтуын зарыгып көткән Хәдичәбикә түтигә өй юышырга килгән бер төркем кыз-кыркын сугыштан кайтып баручы солдатны күреп, таң кала. Хикәянең эчтәлеге карлыгач образына бәйле. Карлыгач – Кытай символикасында яз хәбәрчесе мәгънәсендә тәгалләшә. Ул кешеләргә бәхет өләшә һәм өй янында оя корып, балалы булу бәхетен юрый дип исәпләнә. Шуңа күрә карлыгач кайтуын уңыш китерү йолалары белән бәйләп карыйлар [Жюльен 1999: 212] Шул рәвешле, яз хикәясе дигән көчле позициягә чыгарылган атама хикәядәге төп мәгънәгә басым ясый.

Вакыт образларына салынган эчтәлек (кыш/яз) өмет / өметсезлек бинар оппозициясен алып керә. Каршылык *буранлы* символик укылышлы эпитеты, *дулап узып китте* фигыленең мәгънәви төсмере ярдәмендә көчәйтелә. Хикәяләүче – субъектив образ үзен “мин” дип беренче затта тәкъдим итә. Психологизм алымнары белән баетылган хикәядә хис-кичерешләр сызыгы хикәяләүчегә бәйләнә. Өмет/өметсезлек чигендәге герой яшәү – өмет ягына

чыга (*апрель шаулап тора*), аның хәзерге халәте дөнья өчен ачыклыкны хасил итүче (*тәрәзәм төбемдә*) мәхәббәт көтү кебек билгеләнә (*хәзер майны көтәбез*). Картлар (татар прозасындагы ак сакаллы зирәк карт архетибының модификациясе), Тимерче Бикбай образларына күп хәсрәтләр аша үтеп *(кар күп булды),* көтә белгәннәргә мәхәббәтнең һичшиксез киләчәге *(җәй яхшы килер быел)* әйтелә. Хәдичәбикә түти әлеге чынбарлыкның үзәгенә куела (аның өе юыла). Аның "*унбиш күкәй басып утыра торган казы*" нәселнең киләчәгенә олы ышаныч белән карарга кирәклекне символлаштыра. Каз сурәте – мисырлыларның язуында малай-ул сүзенең иероглифы [Жюльен 1999:87]. Каз – татарның кунак сые да, түшәк-ястыгы да. Димәк, өметне чынбарлык ягына күчерүче "*көзен син табып биргән үзем төсле кара күзле малай" –* киләчәк тормышның мәгънәсе кебек аңлана.

Шулай итеп, автор өмет/өметсезлек каршылыгын үтү юлы турында уйлана, хикәяләүче, Хәдичәбикә түти, кызларны чик халәткә урнаштыра. Хәдичәбикә түтинең өен юарга – күңелен юатырга килгән ихлас күңелле (*яланаяклы*) бер көтү кыз-кыркын – күңелдә туган өметсезлекне юкка чыгарырга ярдәм итүчеләр *(күкәй эченнән чыкмаган бәбкәләрне чистартып бирүчеләр, эре тозны ваклаучылар, кышын юк-бар утын ягып, пычранган өйне, түшәмне кырып-кырып юучылар, егылганда тотып калучылар).*

*Карлыгач* образы кызларга һәм карлыгач оясына бәйле кабатлана (*карлыгачтай кыз)*, гомумиләштерелә (*канат очларына кундырып өйгә бәхет ташый).* Шул рәвешле башка берүнең ярдәме – игелеге кешене өмет ягына алып чыгарга сәләтле, ди автор. Кызлар хәсрәтне тирән яшерә, алар үз ышанычлары белән *(иреннәре кызышуы турында әйтә, тәрәзәдән яртылаш сузылып чыга берсесе, тышкы яктан торып рамнарны юа, әллә кая карап күз кыса)* башкаларны канатландыра, бәхетле, өметле итә *(тәрәзәләр ачык, җил безнең янда, яз безнең янда, кызлар безнең янда)*. Димәк, игелек – күңел кылларың өзелергә торып сыкраганда да башкаларга күрсәтмәү, киресенчә, аларга дәрт өстәү *(галәм сулышы – җил, яңа яшәеш – яз, кызлар – безнең таяныч),* башкалар куанычын күреп сөенә белү: *"Исән генә кайтыр...*

*Карлыгач та кайта дисең ич үзең.” Моны бер кыз әйтте, шуның өчен бу коры өмет кенә түгел, бу, язның үзе төсле, шаулап тәрәзә төбенә килеп җиткән җыр булып яңгырады.”Ачык тәрәзәләр* – кешенең өмет ягына чыгуын белдереп гомумиләшә. Автор ышанып көткәннәр матур оя-нигез корырлык мәхәббәткә лаек, чөнки сине дә сагынып көтүче, хис-кичерешләр белән тулы “юл капчыгы” аскан берәү, һичшиксез, бар, ди. Өметләре чынга ашкан Фәсәхәт исемле кыз теле белән шул хакыйкать әйттерелә.

“Малай белән солдат”(1956) хикәясе рухи таяныч эзләп тормыш юлына чыкканнар халәтен сөйләп бирә. Наил көн дә әтисенең сугыштан кайтуын көтә, урман ягыннан күз дә алмый. Шул яктан кайтып килүче солдатны өенә алып керә, солдат исә малайга әйбәт чаңгылар ясап калдыра.

Наил пространствосы белән башка – малайга билгесез чынбарлыкны *урман-яшәеш* аерып тора. *Әти-таяныч* – яшәеш хәрәкәткә килсен өчен кирәк рухи кыйбла. Кеше үзендәге рухи таянычны тормыш юлына аяк атлагач – *күперне чыккач, каланча* – хәбәр алгач, *“тире толып кигән”* юлдаш Галәви абзыйны очратып киңәшләшкәч, *тимер юлга* – туры юлга баскач, *калай түбәле кызыл станцияне* үтеп, билгесез чынбарлыкка чыккач таба *(кар басып киткән кыр, куян белән тулган урман).* Рухи таяныч эзләү – кешене гел борчып, бимазалап торучы хакыйкать *(әти урман артында мәңелеккә калырга тиеш түгел).* Үзең *ясаган чаңгы* – тормыш юлына тәҗрибәсез килеш япа-ялгыз басып юл ярып карау ул. Юлда очраган тәҗрибәле дус синең киңәшчең, кыйбла күрсәтүче, ярдәм итүче кебек кабул ителә. Әсәр ахырындагы Наил зурларныкы кебек чаңгыга – зурларныкына охшаган үз дөньясына сөенә, бу ышаныч аны беркайчан да ташламаячак. Автор кеше тормыш юлын үзе сыза, рухи таяныч аның үзендә, ярдәм итүче игелекле кеше шул рухны *(йолдызлы бүрек, бил каешы, шашка уены)* бары кузгатып кына җибәрә ала, ди. Тормыш-яшәешнең *“буран котырган”,* куркыныч янаган – *“эт өргән”* шомлы мизгелләрендә кешенең рухи халәте ышанычлы булса гына (*җиделе лампа януы)*, ул сынауларны кичә ала, ятимләнеп калган чынбарлыктан җылы якты

дулкынга көйләнә ала, ди әдип. Солдат киткәннән соң, ана елавы – рухи таяныч эзләүче кешенең сызлануы кебек укыла.

“Чыбыркы” (1956) хикәясендә сугыш вакыйгасы тасвир ителми, ләкин Ф.Хөсни символ ярдәмендә чор фаҗигасен тасвирлый. Хикәя “Сез минем Рәшит исемле малайны белмисездер әле”, – дип хикәяләүченең укучыга мөрәҗәгате белән башлана.

*“Ботинка артыннан ботинка туздырып”, “битен юганда да гауга”* тудыручы бу “ташбашлы” малай белән булган вакыйга, беренче карашка, әллә ни гыйбрәтле түгел: дәү әниләреннән чыбыркы алып кайтып, урамга алып чыга, ямьсез хәлгә юлыга. Ләкин өйдәге *“чыбыркы озынлыгындагы сүзнең”* – гауганың сәбәбе дә шул. Хикмәт шунда: “*төнлә туган бу бәләкәй ташбашлы татардан”* әнисе *“Бетховен, алай да булмаса, янә бер Салих Сәйдәшев әзерләп чыгару”* максатыннан музыка мәктәбенә бирә. Әрләшүнең сәбәбе – әни кешенең: *“Әнә, эт көтүчесе булып үсә бит малаең”,* – дип гарьләнүе. Музыка мәктәбенә әнисе кушуы буенча йөргән бу малай төрле хәйлә корып та карый, ләкин ахырда буйсынырга мәҗбүр була: *“Төнлә туган бу бәләкәй ташбашлы татардан әллә бер Бетховен чыктымы дип йөргәндә, әнисе ноталар сумкасын утынлыктан табып алып керде. Аткан да үзе уенга чыгып качкан. ... Әнисе бик яман кыздырды малайны. Шуннан соң беразга әйбәт кенә йөрде бу, хәтта әлеге шул музыка дигәненнән “биш” ле билгеләре дә күтәреп кайткалады”*.

Рәшитнең авылдан чыбыркы алып килүе шулай итеп конфликтны оештыра. Ата кеше малаеның көтүче булачагына каршы түгел: *“Дөресен әйтим, мин үзем әллә ни шаккатмадым, музыкант булмый икән, көтүче булыр, барыбер түгелмени”*. Гаилә башлыгы хатынына *“каршы әйтеп файда чыкмаслыгын белә, башы иелгәннән иелә бара, ләкин шулай ук маңгае белән идәнгә үк барып төшми”*. Гауганы чыбыркы тавышы өзә: *“Булдырасың, малай, шулай дәвам ит!”, – дим эчемнән генә”.*

Чыбыркы тавышы җәнҗалны туктата, ләкин башка малай кулына килеп эләккән чыбыркы икенче берәүне яралагач, җәнҗал йорттан ишегалдына чыга:

*“Сез ул тәрбиясез малаегызга хуҗа булырга уйлыйсызмы? Әллә милициягә әйтеп, без аны колониягә озатыйкмы?”*

Рәшит чыбыркысына урап почмакка бастырыла, чыбыркы башка шартламас була: *“Әнисе биргән җәзадан мин аны, әлбәттә, коткармадым, ләкин шулай да үз чыбыркысы белән торбага бәйләнеп куелган килеш, беребезгә дә ялынмыйча басып торучы ул малай минем өчен дөньядагы бөтен нәрсәдән дә газизрәк иде”.*

Чемоданнан чыккан, дегетле, тузанлы-балчыклы *“чыккан саен нечкәрә барган, Казаннан Мәскәүгә җитәрлек”* озынлыктагы чыбыркы – Ф.Хөсни уйлап тапкан символ. Автор буйсындыру, мәҗбүр итүнең тәрбияләгәндә һәрвакыт үзен акламавын дәлилли. Шәхси проблема потенциаль эчтәлектә иҗтимагый мотивлаша. Көтүче буласы кешене ялган музыкант иткән, шәхес иреген кыскан бу җәмгыятьнең киләчәге нинди булыр, автор проблеманы шул яссылыкка бора, балалар аудиториясен уйланырга чакыра.

ӘДӘБИЯТ:

1. Жюльен Н. Словарь символов. Иллюстрированный справочник. – Челябинск: Урал LTD, 1999. – 498 стр.

2. Минһаҗева Л.И. XX гасыр татар балалар әдәбияты: үзенчәлекләре һәм үсеш тенденцияләре. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2011. – 312 б.

3. Хөсни Ф.Адәм балалары: хикәяләр һәм повесть. – Казан: Татар. кит.нәшр, 1999.– 288 б.